ГЛАВА НОВОИМЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ИМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 ел ,19 ноябрь. № 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Яңа Имән авылы гражданнарының 2026 елда узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән авылында 2026 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2025 елның 29 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Яңа Имән авылы, Муса Җәлил урамы, 25А йорты адресы буенча урнашкан Яңа Имән авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсәләләрне түбәндәгечә расларга: “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Яңа Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2026 елда 500 сум узара салым җыярга һәм күләмендә кертергә, шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тоторга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

- Яңа Имән авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру).

2. Яңа Имән торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:

- Яңа Имән авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Беларусь МТЗ 82.1 тракторына  (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

-Триммерга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, договор буенча хезмәтенә түләү);

4.Янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу),

"ӘЙЕ"                                   "ЮК?"

3. Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башлыгының «Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Яңа Имән торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәласе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында " 2025 елның 10 ноябрендәге 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә Яңа Имән авылы территориясендә урнашкан махсус мәгүлүмәти стентларда урнаштырырга, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, https://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

РТ Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы:                    Р.Ф.Гараев